

13 майда Тvбән Новгород олкәсе Краснооктябрьск округынын Большерыбушкинский урта мәктәбендә гомуми белем бирv оешмалары укучылары арасында татар телендә «И туган тел, и матур тел» IV тобәкара ижат конкурсы узды.
Конкурста Россиянен 12 субъектыннан белем бирvнен этномәдәни (татар) компоненты булган мәктәп укучылары катнашкан.      Шул исәптән, Мордовияне Ләмберә районы Кривозерье урта мәктәбе татар теле һәм әдәбияты укытучысы Луиза Низаметдин кызы Смакаева, 8 класс укучысы Алина Манеева белән Черемиш топ мәктәбе укытучысы Фазия Фәрит кызы Боярова, 6 класс укучысы Карина Аббясова тәгъдим иттеләр. Әйтеп китәргә кирәк, Фазия Фәрит кызы Боярова дурт ел vткәрелеп килгән тобәкара конкурсынын очесендә катнашкан. Исегезгә тошерәм, Икенче тобәкара ижат конкурсында икенче лаеклы урынны Татар Тавла топ мәктәбе укучысы Муртазина Карина яулаган иде. Быел да, башка еллардагы ярышларда тосле, зурлап укучыларга - катнашучы сертификатлары, укытучыларга– Рәхмәт хатлары белән бергә истәлекле микрофонлы колонкалар белән бvләкләгәннәр. Ә Конкурс Тvбән Новгород олкәсе мәгариф һәм фән министрлыгы тарафыннан Краснооктябрьск муниципаль округы хакимиятенен мәгариф һәм яшьләр эшләре комитеты белән берлектә оештырыла, ә быелгысы 1941-1945 еллардагы Боек Ватан сугышында Жинvнен 80 еллыгы кысаларында vткәрелгән.
Конкурнын максаты - рухи мәдәниятне, патриотик тәрбияне, шулай ук сойләм vсешен һәм нәфис сvзгә кызыксыну формалаштыру, сvзнен шигъри матурлыгын һәм сәнгатьлелеген тоя белvне vстерv.
Укучылар оч номинациядә коч сынаштылар: нәфис уку, татар телендә жырларны ялгыз башкару һәм халык биюләре. Тамашачылар матур чыгышлардан, шигъри әсәрләрне тирән эчтәлекле укудан, патриотик жырлардан, дәртле татар биюләреннән ләззәт алганнар. Чара милли мәдәниятне саклауга һәм vстерvгә зур олеш керткән.